ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 8 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» 2008 елның 22 маендагы 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 3 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш); 2012, № 1, № 12 (I өлеш); 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (II өлеш); 2015, № 11 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 44 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) $13^{1}$ пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«$13^{1}$) гражданнар үз ихтыяҗлары өчен урман фонды җирләрендә әзерләгән агачның характеристикалары турында белешмәләрне дәүләт урман реестрына кертү;»;

2) түбәндәге эчтәлекле $13^{1-1}$ пункт өстәргә:
$13^{1-1}$) гражданнар үз ихтыяҗлары өчен Татарстан Республикасы милкендәге урман кишәрлекләрендә, шул исәптән республика әһәмиятендәге махсус саклануучы табигать территорияләре җирләрендә урнашкан урманнарда әзерләгән агачны исәпкә алу;».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 16 июль
№ 53-ТРЗ